СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19.04.2021 с. Сарманово № 30

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
административ комиссиясен төзү турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының административ комиссиясе турында» 2006 елның 2 мартындагы 53 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитетын административ комиссия төзү өчен вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Сарман муниципаль районы Башкарма комитетына:

- административ комиссия төзергә;
- административ комиссия составын расларга;
- административ комиссиянең эш регламентын расларга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының экологик мәсьәләләр һәм инфраструктура үсеше мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы Рәисе Ф. М. Хөснуллин